ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи, 422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

31.10.2025 с. Куралово 02-02/3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Уставының 24нче статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 нче елның 11 нче ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылы гражданнарына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыенның беренче этабын билгеләргә.
2. 2025 нче елның 11 нче ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылы гражданнарына үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җыенның икенче этабын билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүлү.
1 нче этап: Рус Борнашы авылының Зур урамы, Цветочная урамы, Малая урамы халкы
2 нче этап: Рус Борнашы авылының Совет урамы, Дальняя урамы, Заречная урамы халкы

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегенең Рус Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (билгеләнгән урынга илтеп җиткереп, асфальт гранулат сатып алу).

«ӘЙЕ» « ЮК»

5. Гражданнар җыеннарын үткәрергә:
1 этап: Рус Борнашы авылының Зур урамы буенча 4нче йорт янында
2 этап: Рус Борнашы авылы Заречная урамы буенча 1 нче йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово  авыл җирлеге башлыгы                                        Р.Е.Тарасов